**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“22” ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Яңа Өҗем торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районың Кышлау авыл җирлеге территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1). Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Яңа Өҗем авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту һәм кисү;

2). Җирләү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Яңа Өҗем авылы зиратларына элмә такталар һәм хуҗалык материаллары сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Яңа Өҗем авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Яңа Өҗем авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.